## Аңлатма язуы

Эш программасы Казан шәһәре Совет районының муниципаль автоном мәктәпкәчә белем учреждениесе «352 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» өчен төзелгән.

Балалар бакчасында рус балаларына татар телен өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү, төрле яктан үсеш өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора.

Эш программасы Федераль дәүләт белем стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

Әлеге эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелгән:

**Федераль җирлектә:**

-“Россия Федерациясендә белем турында” федераль закон - 29.12.2012 N 273-ФЗ (07.05.2013 үзгәртүләр кертелеп, 19.05.2013 гамәлгә кергән),

-Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Министрлыгы һәм Фән министрлыгының 2013 елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган;

СП 2.4.3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденными постановлением главного санитарного врача от 28.09.2020 № 28 приказом Минобрнауки от 31.07.2020 № 373 «Обутверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования»,-“ (Тәрҗемәсе СП 2.4.3648-20 “Балалар һәм яшьләр өчен төзелгән тәрбия һәм белем бирү, ял һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар – эпидемиологик таләпләр “ баш санитар табип карары нигезендә раслана 28.09.2020 № 28, “Оештыру тәртибен белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыру төп белем бирү программасы- мәктәпкәчә белем бирү программасы нигезендә раслау" Минобрнаук приказы 31.07.2020 №373

**Төбәк җирлегендә:**

- Татарстан Республикасының 2013 ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;
- Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм башка телләр турында” Законы;

-Мәгариф һәм Фән Министрлыгының туган һәм татар телләрен балалар бакчаларында өйрәтү эшчәнлеге буенча методик тәкъдимнәре буенча боерыгы ( 2018ел)

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2015–2025 елларда мәгарифне үстерү стратегиясе (29.05.2015, №996-р)

**Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җирлегендә:**-Казан шәһәре Совет районы «352 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе уставы;

- Казан шәһәре Совет районы «352 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе.

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү

буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус телле балаларны татарчага өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды.

Балалар бакчасында татар теленә өйрәтү программасы (эш программасы) “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт таләпләре”нә (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карары нигезендә расланган) нигезләнеп төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле һәм башка милләт балаларын татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. З.М.Зарипова авторлыгында “Татарча сэйләшәбез” укыту-методик кулланмаларына нигезләнеп өйрәтелә. УМК“Минем өем” (4-5 яшь), “Уйный – уйный үсәбез” (5-6 яшь), “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” (6 - 7 яшь) проектларын үз эченә ала.

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар, интерактив уеннар тора.

Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртелә, яңа алымнар кертелә, баетыла.

Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр, сюжетлы рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла.

Эш программасы өч бүлектән (максатчан, эчтәлекле, оештыру) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота.

Эш программасының кушымта өлешендә эш көне бүленеше, шөгыльләр челтәре, еллык эш план , милли состав .